**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 22 сентябрь | № 674

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 ел, 27 ноябрь, ТРЗ-107 нче, «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2014 ел, 27 ноябрь, ТРЗ-109 нчы, «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 ел, 20 ноябрь, ТРЗ-97 нче, «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2015 ел, 20 ноябрь, ТРЗ-98 нче Татарстан Республикасы законнарын үтәү йөзеннән, 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны модернизацияләү һәм үстерү турында» 2016 ел, 3 сентябрь, 614 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның I бүлегендәге «Татарстан Республикасында махсуслаштырылган ярдәм күрсәтү системасының структур үзгәрешләре»

бүлекчәсенең егерме алтынчы абзацында, I бүлекнең ундүртенче, унсигезенче, егерме сигезенче, утыз бишенче абзацларында һәм «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларны) үстерү» дигән 5 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы» бүлекчәсенең тугызынчы абзацында, «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» дигән 10 нчы ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы» бүлекчәсенең егерме сигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тернәкләндерү дәвалавы республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләрен «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортының «Ярдәмче программалар исемлеге», «Программаны финанслау күләмнәре*», «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре**» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1 нче ярдәмче программа. «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү».<br>2 нче ярдәмче программа. «Махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү».<br>3 нче ярдәмче программа. «Дәүләт-шәхси партнерлыгын үстерү».<br>4 нче ярдәмче программа. «Ана һәм бала сәламәтлеген саклау».<br>5 нче ярдәмче программа. «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларны) үстерү».<br>6 нчы ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга».<br>7 нче ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү».<br>8 нче ярдәмче программа. «Дарулар белән тәэмин итү системасын, шул исәптән амбулатория шартларында камилләштерү».<br>9 нчы ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклауда мәгълүматлаштыруны үстерү».<br>10 нчы ярдәмче программа. «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру системасын камилләштерү».<br>11 нче ярдәмче программа. «2014 – 2016 елларга Татарстан |

| | |
|---|---|
| | Республикасының сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү».<br>12 нче ярдәмче программа. «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» |
| Программаны финанслау күләмнәре* | Программа буенча барлыгы – 714 379 395,3 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 382 595 712,6 мең сум, шулардан:<br>алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 7 565 149,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шул исәптән:<br>2013 ел – 4 485,2 мең сум,<br>2014 ел – 2 327 823,7 мең сум,<br>2015 ел – 3 389 332,0 мең сум,<br>2016 ел – 862 024,9 мең сум,<br>2017 ел – 964 961,1 мең сум,<br>2018 ел – 5 294,9 мең сум,<br>2019 ел – 5 512,0 мең сум,<br>2020 ел – 5 715,9 мең сум;<br>алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 53 174 154,3 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 5 660 285,2 мең сум,<br>2014 ел – 4 299 389,0 мең сум,<br>2015 ел – 8 256 404,5 мең сум,<br>2016 ел – 11 078 404,1 мең сум,<br>2017 ел – 3 090 045,7 мең сум,<br>2018 ел – 6 662 237,6 мең сум,<br>2019 ел – 6 935 389,4 мең сум,<br>2020 ел – 7 191 998,8 мең сум;<br>алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 151 076 979,6 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 15 943 700,6 мең сум,<br>2014 ел – 18 237 595,8 мең сум,<br>2015 ел – 19 525 405,6 мең сум,<br>2016 ел – 19 450 882,3 мең сум,<br>2017 ел – 21 368 065,4 мең сум,<br>2018 ел – 18 598 428,6 мең сум,<br>2019 ел – 18 849 315,1 мең сум,<br>2020 ел – 19 103 586,2 мең сум;<br>алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган |

| | |
|---|---|
| | мәҗбүри медицина иминияте акчасы – 170 779 429,0 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 13 915 012,8 мең сум,<br>2014 ел – 17 892 587,8 мең сум,<br>2015 ел – 19 349 897,9 мең сум,<br>2016 ел – 19 292 951,3 мең сум,<br>2017 ел – 22 664 150,3 мең сум,<br>2018 ел – 24 635 948,8 мең сум,<br>2019 ел – 25 867 746,4 мең сум,<br>2020 ел – 27 161 133,7 мең сум;<br>өстәмә ихтыяҗ – 331 783 682,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән, шул исәптән:<br>2013 ел – 8 241 505,5 мең сум,<br>2014 ел – 17 181 285,9 мең сум,<br>2015 ел – 16 243 661,7 мең сум,<br>2016 ел – 36 115 745,6 мең сум,<br>2017 ел – 56 202 291,2 мең сум,<br>2018 ел – 59 641 235,4 мең сум,<br>2019 ел – 66 028 923,1 мең сум,<br>2020 ел – 72 129 034,3 мең сум.<br><br>1 нче ярдәмче программа. «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү»*<br>Барлыгы – 76 081 441,9 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 70 225 766,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 5 855 675,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>2 нче ярдәмче программа. «Махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү»*<br>Барлыгы – 286 892 067,1 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 227 784 978,2 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 59 107 088,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>3 нче ярдәмче программа. «Дәүләт-шәхси партнерлыгын үстерү»*<br>Барлыгы – 4 321 478,5 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан чыганагы билгеләнгән – 4 321 478,5 мең сум |

| | |
|---|---|
| | (2013 елдан 2020 елга кадәр).<br>4 нче ярдәмче программа. «Ана һәм бала сәламәтлеген саклау»*<br>Барлыгы – 7 811 907,3 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 4 417 553,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 3 394 353,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>5 нче ярдәмче программа. «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларны) үстерү»*<br>Барлыгы – 6 610 795,6 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 1 964 285,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 4 646 510,0 мең сум, чыганагы билгеләнмәгән (2013 елдан 2020 елга кадәр).<br><br>6 нчы ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга»*<br>Барлыгы – 255 849,4 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан чыганагы билгеләнгән – 255 849,4 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр).<br><br>7 нче ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү»*<br>Барлыгы – 199 233 994,2 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр) өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып, шулардан:<br>чыганагы билгеләнгән – 15 184 461,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 184 049 533,2 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>8 нче ярдәмче программа. «Дарулар белән тәэмин итү системасын, шул исәптән амбулатория шартларында камилләштерү»*<br>Барлыгы – 66 936 872,4 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 5 964 681,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 60 972 190,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>9 нчы ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклауда |

| | |
|---|---|
| | мәгълүматлаштыруны үстерү»*<br>Барлыгы – 1 607 720,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан өстәмә ихтыяҗ – 1 607 720,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>10 нчы ярдәмче программа. «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру системасын камилләштерү»*<br>Барлыгы – 53 757 731,6 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 41 607 121,5 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 12 150 610,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>11 нче ярдәмче программа. «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү»*<br>Барлыгы – 1 274 630,8 мең сум, шулардан чыганагы билгеләнгән – 1 274 630,8 мең сум (2014 елдан 2016 елга кадәр).<br><br>12 нче ярдәмче программа. «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»<br>Барлыгы – 9 594 905,6 мең сум, шулардан чыганагы билгеләнгән – 9 594 905,6 мең сум (2015 – 2016 еллар) |
| Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре** | 2020 елда барлык сәбәплләрдән үлү күрсәткечен 1000 кешегә 11,5 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда аналар үлеме күрсәткечен тере туган 100 мең кешегә 8,8 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда сабыйлар үлеме күрсәткечен тере туган 1000 кешегә 6,0 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлү күрсәткечен 100 мең кешегә 630,4 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда юл-транспорт һәлакәтләреннән үлү күрсәткечен 100 мең кешегә 15,0 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда шешләрдән (шул исәптән яман шештән) үлү күрсәткечен 100 мең кешегә 182,1 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда туберкулездан үлү күрсәткечен 100 мең кешегә 6,0 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда алкогольле продукция куллануны (абсолют алкогольгә күчергәндә) бер елда халыкның җан башына |

| | |
|---|---|
| | 9 литрга кадәр киметү;<br>2020 елда өлкән яшьтәге халык арасында тәмәке тарту таралуны 31,3 процентка киметү;<br>2020 елда балалар һәм яшүсмерләр арасында тәмәке тарту таралуны 21 процентка киметү;<br>2020 елда туберкулез белән авыручылар дәрәҗәсен 100 мең кешегә 34,7 очракка кадәр киметү;<br>2020 елда табиблар белән тәэмин ителүне 10 мең кешегә 29,3 очракка кадәр арттыру;<br>2020 елда табиблар һәм урта медицина персоналы чагыштырмасы 3 кә 1;<br>2017 елда медицина хезмәтләре күрсәтүче (медицина хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче) Татарстан Республикасы медицина оешмаларының югары медицина (фармацевтика) яки башка югары белемле табиблары һәм хезмәткәрләре уртача эш хакының Татарстан Республикасында уртача эш хакының чагыштырмасын 200 процентка кадәр җиткерү;<br>2017 елда урта медицина (фармацевтика) персоналы (медицина хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче персонал) уртача эш хакының һәм Татарстан Республикасында уртача эш хакының чагыштырмасын 100 процентка кадәр җиткерү;<br>2017 елда кече медицина персоналы (медицина хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче персонал) уртача эш хакының һәм Татарстан Республикасында уртача эш хакының чагыштырмасын 100 процентка кадәр җиткерү;<br>2020 елда туганда көтелә торган гомер озынлыгын 75 яшькә кадәр арттыру;<br>2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларының гомуми санында биналары авария хәлендә булган яки капиталь ремонт таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмалары өлешен 30 процентка кадәр киметү;<br>2020 елда эшкә яраклы яшьтәге кешеләр үлеме күрсәткечен тиешле яшьтәге 100 мең кешегә 491,0 очракка кадәр киметү»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа буенча барлыгы – 714 379 395,3 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:

чыганагы билгеләнгән – 382 595 712,6 мең сум, шулардан:

алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет

акчасы – 7 565 149,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 53 174 154,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 151 076 979,6 мең сум;

алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган ММИ акчасы – 170 779 429,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

өстәмә ихтыяҗ – 331 783 682,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программага түбәндәге эчтәлекле 12 нче ярдәмче программа өстәргә:

«12 нче ярдәмче программа. «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» (алга таба – ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы (дәүләт заказчысы – яраштыручысы), аны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| Җаваплы үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы,<br>«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (килешү буенча) |
| Бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| | |
|---|---|
| Бюджет акчасын алучылар | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» ДКУ,<br>Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (килешү буенча) |
| Ярдәмче программаның максатлары | Медицина ярдәменнән һәркем файдалана алуны тәэмин итү һәм медицина хезмәтләренең нәтиҗәлелеген арттыру |
| Ярдәмче программаның бурычлары | Сәламәтлек саклауны оештыруның системалылыгын тәэмин итү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2015 – 2020 еллар. Ярдәмче программа бер этапта тормышка ашырыла |
| Ярдәмче программаны финанслар белән тәэмин итү күләмнәре | Барлыгы – алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 9 594 905,6 мең сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт, шулардан:<br>2015 елда – 3 094 033,8 мең сум;<br>2016 елда – 6 500 871,8 мең сум.<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш |
| Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларының гомуми санында биналары авария хәлендә булган яки капиталь ремонт таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмалары өлешен 30 процентка кадәр киметү |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең агымдагы хәле тасвирламасы, әлеге өлкәдә төп проблемалар һәм аның үсеш фаразы

Соңгы биш ел эчендә сәламәтлек саклау оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга 15 млрд.сумнан артык акча бүлеп бирелде, шулардан төбәк югары технологияле медицина үзәкләре төзүгә 10 млрд.сумнан артык акча кертелде.

Түбәндәгеләр эксплуатациягә кертелде: Чаллы шәһәрендә «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында Кичектергесез медицина үзәге, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ПЭТ үзәге, «Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Татарстан Республикасы

Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» («Азино») дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 3 нче балалар поликлиникасы, Казан шәһәрендә балалар хосписы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең яңа дәвалау корпусы (Себер тракты ур., 31 нче йорт), Лениногорск үзәк район хастаханәсенең балалар стационары бинасы, «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык-гинекология корпусы, «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар стационары.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 10 март, 179 нчы карары белән расланган «2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү» программасы кысаларында иң эре республика клиникалары һәм 31 үзәк район хастаханәсе, 40 авыл табиблар амбулаторияләре яңартылды. 199,4 мең.кв.метр мәйданнар ремонтланды, 21 мең берәмлектән артык заманча медицина җиһазлары сатып алынды, шул исәптән 261 берәмлек – санитария автотранспорты.

Капиталь ремонт үткәрелгәннән соң һәм заманча җиһазлар белән җиһазландырылганнан соң, үзәк район хастаханәләренең ашыгыч медицина ярдәме пунктлары белән кабул итү-диагностика бүлекләре яңача эшләп китте. Шок хәлендәге авырулар, реанимация, универсаль операция блоклары оештырылды, диагностика һәм изоляция блоклары, вакытлыча яткан һәм өзлексез күзәтү астында булган авырулар палаталары төзелде. Болар барысы госпитальләштерелә торган авырулар агымын кичектергесез булу, хәлнең авырылыгы, йогышлылык принцибы буенча бүлергә, бөтен диагностика ресурсларын тупларга һәм госпитальгә кадәрге этапны кыскартырга, хастаханәгә килгәннән соң беренче минуттан ук реанимация ярдәме, кичектергесез ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудырырга, стационарны алыштыру технологияләрен гамәлгә кертергә, пациентлар өчен тагын да уңайлы шартлар тудырырга мөмкинлек бирде.

Бүгенге көндә авылда медицина персоналының эшләве һәм пациентларның ятуы өчен тиешле шартлар булдырыла. Ел саен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм «Нефтемаш Азнакай заводы» ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә беренчел сәламәтлек саклау челтәре объектларының яңа төрләре үзләштерелә. Мәсәлән, 2012 елда модульле фельдшерлык-акушерлык пунктлары белән беррәттән, беренче модульле табиблар амбулаториясе төзелде, 2013 елда модульле патология-анатомия бүлекләре төзелә башлады. 2015 елдан башлап, халыкка амбулатория-поликлиника ярдәмен якынайту өчен, яңа микрорайоннарда биналарның беренче катларында гомуми практика табиблары һәм участок педиатрлары өчен үзәкләр ачу күздә тотыла.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары һәм бурычлары, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Максатлар: медицина ярдәменнән һәркем файдалана алуны тәэмин итү һәм медицина хезмәтләренең нәтиҗәлелеген арттыру.

Куелган максатларга ирешү өчен, сәламәтлек саклауны оештыруның системалылыгын тәэмин итү бурычын хәл итәргә кирәк.

Ярдәмче программа бер этапта тормышка ашырыла – 2015 – 2020 еллар.

**Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы**

2015 елда Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау объектларының матди-техник базасын ныгыту максаты белән түбәндәге чаралар үткәрелде:

«ТР ССМ Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең педиатрия офисын урнаштыру өчен җиһазлар сатып алып, Казан шәһәре, Фучик ур., 133 нче йорт адресы буенча урнашкан биналарны капиталь ремонтлау;

алга таба «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив ярдәм бүлеген урнаштыру өчен, Казан шәһәре, Сафиуллин урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан бинада ремонт эшләре үткәрү, медицина җайланмалары, җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;

медицина җайланмалары һәм җиһазлар сатып алып, «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

Чаллы шәһәрендәге «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау (балалар стационарының «Г» блогы);

«Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

җиһазлар һәм җайланмалар сатып алып, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен капиталь ремонтлау;

Казан шәһәренең «11 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника бүлеген капиталь ремонтлау;

«Кайбыч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау һәм җайланмалар, җиһазлар сатып алу;

«Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

медицина техникасы һәм җайланмалар сатып алып, «Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 нче балалар поликлиникасын капиталь ремонтлау;

Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар йогышлы авырулары корпусы бинасын капиталь ремонтлау;

Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 нче балалар поликлиникасы

бинасының фасадын төзекләндерү;

Чаллы шәһәренең Чулман пр., 61/31 нче йорт адресы буенча урнашкан «Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (3 нче бүлек) бинасына керә торган төркемне һәм түбәсен проектлаштыру һәм капиталь ремонтлау;

Чаллы шәһәренең Романтиклар бульвары, 54/05 нче йорт адресы буенча урнашкан «Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (4 нче бүлек) бинасына керә торган төркемне һәм түбәсен проектлаштыру һәм капиталь ремонтлау;

медицина җайланмалары һәм җиһазлар сатып алып, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасын капиталь ремонтлау;

медицина җайланмалары һәм җиһазлар сатып алып, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык корпусын капиталь ремонтлау;

«Спас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе стационарын капиталь ремонтлау;

акушерлык-гинекология бүлеген урнаштыру өчен, «Урыссу үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасы бүлмәләрен капиталь ремонтлау;

«Чистай медицина училищесе» урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең спорт залын капиталь ремонтлау;

«Казан медицина көллияте» урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең спорт залын капиталь ремонтлау;

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар стационары бинасын капиталь ремонтлау;

«Актаныш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникасы бинасына проект-тикшеренү эшләре үткәрү һәм капиталь ремонтлау;

Казан шәһәренең «16 нчы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

«Арча үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең икенче дәвалау корпусын капиталь ремонтлау;

җиһазлар һәм медицина җайланмалары сатып алып, «Баулы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

Казан шәһәренең Себер тракты ул., 31 нче йорт «Ашыгыч медицина ярдәме 1 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең патология-анатомия корпусын төзү;

«Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

«Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасын урнаштыру өчен, «83 нче һөнәр училищесы» һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең элеккеге бинасын капиталь ремонтлау;

«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык-гинекология корпусын капиталь ремонтлау;

Түбән Кама шәһәре дәвалау корпусының профилен 2 нче поликлиникага үзгәртү;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарының фасадларын архитектура яктыртуы буенча эшләр үткәрү;

Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлмәләрен капиталь ремонтлау;

«7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең бала табу йорты бинасы фасадын капиталь ремонтлау;

«Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар бүлеген капиталь ремонтлау;

«Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

«Тәтеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең стоматология поликлиникасын һәм поликлиникасын капиталь ремонтлау;

«Килдураз авылы республика балалар санаторие» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең ягып җылыту, су белән тәэмин итү, канализация системаларын ремонтлау;

«Зеленодольск медицина училищесы» Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең бинасын ремонтлау;

«Республика наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе «Большие ключи» тернәкләндерү наркология үзәге бинасының түбәсен ремонтлау;

«Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын ремонтлау;

«7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 нче поликлиника бүлеген капиталь ремонтлау;

Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен капиталь ремонтлау һәм җиһазлар белән тәэмин итү;

«Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе стационарын капиталь ремонтлау;

«Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен капиталь ремонтлау.

2016 елда түбәндәгеләр планлаштырыла:

«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

«Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном

сәламәтлек саклау учреждениесе бүлмәләрен проектлаштыру һәм капиталь ремонтлау;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең травматология үзәгендә ремонт эшләре үткәрү;

«Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын реконструкцияләү;

Казан шәһәренең «5 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

медицина җиһазлары сатып алып, «Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

«Баулы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлауны тәмамлау;

«Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең лифт шахтасын төзү;

медицина җайланмалары һәм җиһазлар сатып алып, «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника бинасын капиталь ремонтлау;

«Спас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

«Академик В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 18 нче стационар суд-медицина экспертизасы бүлеге бүлмәләрендә ремонт эшләре;

«Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

«Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен капиталь ремонтлау;

Чаллы шәһәрендә «2 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең стационар һәм поликлиника биналарын капиталь ремонтлау;

«Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе акушерлык корпусын ремонтлауны тәмамлау;

медицина җайланмалары һәм җиһазлар сатып алып, «Минзәлә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау;

«Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең операцияләр блогын реконструкцияләүне тәмамлау;

җиһазлар сатып алып, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасының бүлмәләрен ремонтлау;

«Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау;

«Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын капиталь ремонтлауны тәмамлау;

Чаллы шәһәрендә «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек

саклау учреждениесе бинасының бүлмәләрендә ремонт эшләре;

Казан шәһәренең «11 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника бүлеген капиталь ремонтлау;

Казан шәһәренең «21 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен урнаштыру өчен, Р.Зорге ур., 103 нче йорт адресы буенча бина төзелешен тәмамлау;

«Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Түбән Камадагы филиалы бинасын керамогранит белән тышлап, тышкы диварларын җылыту;

«7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 нче поликлиника бүлеге бинасын капиталь ремонтлау;

«Әтнә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе хастаханә комплексының поликлиника өлешен һәм бинасы түбәсен капиталь ремонтлау;

Иннополис шәһәрендә медицина үзәге төзү;

«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасының социаль тармакларын һәм иҗтимагый инфраструктурасын үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында сәламәтлек саклау объектларын модернизацияләү, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чаралары.

Әлеге концепциянең төп юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

сәламәтлек саклау объектларын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау;

яңа сәламәтлек саклау объектлары төзү;

мәйданнардан оптималь файдалану;

сәламәтлек саклау объектларының матди-техник базасын ныгыту;

сәламәтлек саклау объектларында энергетика ресурсларын куллануны киметү.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Барлыгы – Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән 9 594 905,6 мең сум, шул исәптән:

Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт, шулардан:

2015 елда – 3 094 033,8 мең сум;

2016 елда – 6 500 871,8 мең сум, шул исәптән «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасының социаль тармакларын һәм иҗтимагый инфраструктурасын үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында сәламәтлек саклау объектларын модернизацияләү, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чараларына, шулардан 2016 елда – 4 381 060,0 мең сум.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш.

# Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Ярдәмче программа чаралары буенча финанслау

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | чыганак | күләме, мең сум | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| Медицина ярдәменнән һәркем файдалана алуны тәэмин итү һәм медицина хезмәтләренең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Сәламәтлек саклауны оештыруның системалылыгын тәэмин итү | Сәламәтлек саклау объектларының матди-техник базасын ныгыту | ТР ТАһ ТКХМ, ТР ССМ | 2015 – 2020 еллар | 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларының гомуми санында биналары авария хәлендә булган яки капиталь ремонт таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау оешмалары өлеше, процент | 52,3 | 50,0 | 45,5 | 41,1 | 37,8 | 34,2 | 30,0 | Татарстан Республикасы бюджеты | 3 094 033,8 | 2 119 811,8 | - | - | - | - |
| | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 – | ТР ФМ, ТР ИМ, ТР ТАһ ТКХМ, ТР ССМ, «ИВФ» КБО (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар | | | | | | | | | | - | 4 381 060,0 | - | - | - | -»; |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2020 елларга Татарстан Республикасының социаль тармакларын һәм иҗтимагый инфраструктурасын үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында сәламәтлек саклау объектларын модернизацияләү, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чаралары | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Программаның «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү» дигән 1 нче ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре*» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре* | Барлыгы – 76 081 441,9 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 70 225 766,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан:<br>алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 3 840 710,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 504 809,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 2 939 668,5 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган мәҗбүри медицина иминияте акчасы – 61 940 579,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 5 855 675,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән»; |

1 нче ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче – җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Барлыгы – 76 081 441,9 мең сум* (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:

чыганагы билгеләнгән – 70 225 766,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан:

алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 3 840 710,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 504 809,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

алдан бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 2 939 668,5 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

алдан бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган мәҗбүри медицина иминияте акчасы – 61 940 579,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

өстәмә ихтыяҗ – 5 855 675,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.»;

«Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм ярдәмче программа чаралары буенча финанслау*» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

# «Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм ярдәмче программа чаралары буенча финанслау*

| Бурыч исеме | Төп чаралар исемнәре | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | чыганак | күләме, мең сум 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм авыруларны профилактикалау хисабына халыкның актив гомер озынлыгын арттыру; миокард инфаркты һәм инсульт белән авырулар санын киметү. Яман шеш белән авыручыларны авыруның I - II стадияләрендә билгеләүне арттыру; туберкулезлары башлангыч стадиядә билгеләнгән авырулар өлешен арттыру; алкоголизм, наркомания белән авырулар санын киметү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Йогышсыз авыруларның медицина профилактикасы системасын үстерү һәм Татарстан Республикасы халкында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, шул исәптән аеруча әһәмиятле куркыныч факторларының таралуын киметү | 1.1. Йогышсыз авыруларның медицина профилактикасы системасын үстерү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, шул исәптән балаларда. Бәйлелекләр үсешен профилактикалау, тәмәке тартуны, алкоголь, наркотик чаралары һәм психоактив матдәләр куллануны киметүне кертеп, шул исәптән балаларда | ТР ССМ[1], ТР ЯЭСМ, ТР МФМ, ТР ММ, ТР ХһСЯМ, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «КДМУ» ЮһББ ДБМУ (килешү буенча), Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «КДМА» ӨһББ ДБМУ (килешү буенча) | 2013 – 2020 годы | Хисап елында тиешле контингент арасыннан балаларга профилактика медицина тикшерүе үткәрү, % | 0,0 | кимендә 50 | кимендә 50 | кимендә 50 | кимендә 90 | кимендә 90 | кимендә 90 | кимендә 90 | кимендә 90 | Татарстан Республикасы бюджеты | 50 896,4 | 45 138,1 | 66 160,8 | 114 416,1 | 64 996,1 | 59 237,3 | 61 666,0 | 63 947,6 |
